ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 7 июле** **Чистай шәһәре** **№ 446**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Чистай муниципаль районы территориясендә мәдәни мирас объектларын саклау зоналары һәм истәлекле урыннар чикләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карау комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 22 июнендәге 422 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Чистай тарихи үзәге» истәлекле урыны һәм саклау предметы» региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау турында» 2021 елның 21 декабрендәге 335-П номерлы Татарстан Республикасы комитеты боерыгы нигезендә, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру, Чистай муниципаль районы территориясендә мәдәни мирас объектларын һәм тарихи-шәһәр төзелеше мохитен саклап калу мәсьәләләрен оператив карау максатларында, шулай ук кадрлар үзгәрешләре белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Чистай муниципаль районы территориясендә истәлекле урыннар һәм мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карау комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 22 июнендәге 422 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Чистай муниципаль районы территориясендә истәлекле урыннар һәм мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карау комиссиясе составын (2 нче кушымта) яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт өстәргә: «Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2016 елның 15 гыйнварындагы 13 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән территорияләр чикләрендә Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы тарафыннан Чистай шәһәре тарихи җирлегенең саклау предметын раслаганчы Чистай шәһәрендәге объектларны сүтүгә мораторий билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б.

Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «7» июлендәге
446 номерлы карарына
2 нче кушымта

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ИСТӘЛЕКЛЕ УРЫННАР ҺӘМ МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ ЗОНАЛАРЫ ЧИКЛӘРЕНДӘ ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ ЭШЧӘНЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕН КАРАУ БУЕНЧА КОМИССИЯ СОСТАВЫ**

Комиссия рәисе:

Хәсәнов
Эдуард Рөстәм улы - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

Комиссия рәисе урынбасарлары:

Рәхимов
Илдар Фаил улы - Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе

Емельянов
Павел Борисович -Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары

Комиссия секретаре:

Силайчев
Денис Павлович - Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы

Комиссия әгъзалары:

Балтусова
Олеся Александровна - Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе
(килешү буенча)

Кудряшов
Владимир Николаевич - Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары
(килешү буенча)

Шумилов
Андрей Александрович - Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы

Исхакова

Марина Юрьевна - Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе

Вәлиев
Наил Мансур улы - Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе әгъзасы, филология фәннәре докторы, профессор

Печенкин
Александр Вячеславович - «Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәби музей тыюлыгы» ТР ДБУК директоры

Зарипов
Роберт Наил улы - Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы

Кронберг
Сергей Борисович - Чистай шәһәрендә яшәүче